| | |
|---|---|
| **ГЛАВА ПЕТРОВСКО-ЗАВОДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕТРОВСКИЙ ЗАВОД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |
| **2025 ел 14 ноябрь** | **№6** |

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Пробуждение авылы гражданнарының үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Иҗтимагый хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Пробуждение авылы гражданнары җыенын авылы клубы бинасында 2025 елның 29 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: 80 яшьтән өлкән кешеләрдән кала, Петровский Завод авыл җирлеге Пробуждение авылында теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2026 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

1. Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (Пробуждение торак пунктында урам тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау (лампалар, таймерлар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру):

2. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тозү, ремонтлау, тоту (Пробуждение торак пунктында юлларны кардан чистарту (Беларус МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, чыгым материаллары сатып алу, килешү буенча йөртүче хезмәтләре өчен түләү); Пробуждение торак пунктының Татарстан урамының юлын ремонтлау (таш белән капланган чокырлы ремонт, вак таш сатып алу, ташу, салу, грейдерлау, килешү буенча хезмәтләргә түләү), күпер ремонтлау

(материаллар сатып алу, килешү буенча хезмәтләргә түләү);

3. Пробуждение торак пунктында традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (үлән чабу, триммерлар өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);

4. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Пробуждение торак пункт территориясендә үлән чабу, (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү); триммерлар өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу; тракторны тоту (Беларус МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьлар, чыгым материаллары сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү»

ӘЙЕ ЮК?».

3. Әлеге карарны Петровский Завод авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:// sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә игълан итәргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Петровский Завод
авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Нуртдинов